РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ул. Ленина, д. 31**
**село Верхние Кибя-Кози,**
**422083**
**тел.(884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Ленин урамы, 31 енче йорт,**
**Югары Кибәхуҗа авылы,**
**422083**
**тел. (884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№24**

**КАРАР**
**«25» июля 2019 г.**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Югары Кибәхуҗа авылы, Ленин урамы, 31 йорт, мәдәният йорты бинасы янында мәгълүмат стенды;
- Максабаш авылы, Татарстан урамы, 27 йорт, мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стенды;
- Төрек-Тәмте авылы, Үзәк урамы, кибет бинасында мәгълүмат стенды;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Югары Кибәхуҗа авылы, Ленин урамы, 31 йорт, Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Югары Кибәхуҗа авыл

җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Югары Кибәхуҗа авыл
җирлеге башлыгы                                                  Ф.Р. Мәхмүтов